КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 март г.Казань № 212

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә иң яхшы оешмасы» республика конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 ел, 16 июль, 521 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә иң яхшы оешмасы» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә иң яхшы оешмасы» республика конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 ел, 16 июль, 521 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә иң яхшы оешмасы» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Конкурс түбәндәге катнашучыларның 5 категориясе буенча үткәрелә:

I категория – 150 мең кв.метрга кадәр торак фондына хезмәт күрсәтүче оешмалар;

II категория – 150 меңнән 300 мең кв.метрга кадәр торак фондына хезмәт күрсәтүче оешмалар;

III категория – 300 меңнән 750 мең кв.метрга кадәр торак фондына хезмәт күрсәтүче оешмалар;

IV категория – 750 меңнән 1 500 мең кв.метрга кадәр торак фондына хезмәт күрсәтүче оешмалар;

V категория – 1 500 меңнән һәм аннан күбрәк кв.метрга кадәр торак фондына хезмәт күрсәтүче оешмалар.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Конкурс ел саен Министрлык тарафыннан «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмалар бердәмлеге» ассоциациясе үз-үзен җайга салучы оешмасы белән берлектә үткәрелә.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Конкурсны үткәрү тәртибе һәм аның йомгаклары массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртыла һәм Министрлык белән «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмалар бердәмлеге» ассоциациясе үз-үзен җайга салучы оешмасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырыла.»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Конкурс кысаларында Министрлык һәм «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмалар бердәмлеге» ассоциациясе үз-үзен җайга салучы оешмасы тарафыннан бүләкләүләрнең башка төрләре гамәлгә куелырга мөмкин.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин